РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«08» сентябрь 2025 ел** **№ 5**

2024 елның 22 ноябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2024 елның 22 ноябрендәге 2 нче номерлы «2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, **карар итәм:**

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Илбәк авылы, Ә. Вәлиев ур., 50 йорт адресы буенча урнашкан Илбәк авылы мәдәният йорты бинасында 2025 елның 19 сентябрендә 09.00 сәгатькә, 2024 елның 22 ноябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2024 елның 22 ноябрендәге 2 нче номерлы «2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2024 елның 22 ноябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

турында», 2024 елның 22 ноябрендәге 2 нче номерлы «2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

- Илбәк торак пунктында урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Илбәк авылында Ә. Вәлиев урамындагы 35 нче йорттан 39 нчы йортка кадәр вак таш түшәлгән юлны профильләштерү);
- Илбәк торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Р.К.Галимҗанова